МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.06.2025 Казан ш. № 335-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертүгә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.06.2025 № 335-пр боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.03.2023 № 212-пр, 26.09.2023 № 684-пр, 11.04.2024 № 207-пр, 07.11.2024 № 651-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

3.6.3 пунктта:

дүртенче абзацта «Бүлек белгече әзерләгән» сүзләрен «Гариза бирүче таләбе буенча документларны кабул итүдән баш тарту язмача әзерләнә.» сүзләре белән алмаштырырга;

җиденче абзацны «телдән» сүзеннән соң «(язмача)» сүзе белән тулыландырырга;

3.9.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.8. Бүлек белгече күрсәтелгән проектлар буенча кимчелекләр бәян ителгән хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм җиренә җиткереп эшләнгән җир кишәрлеген бирү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен кабаттан хокук идарәсе башлыгына юллый.»;

Административ регламентка 6 нчы кушымтаның 13 пунктында «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга:

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 21.06.2022 № 380-пр боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.09.2022 № 534-пр, 11.04.2024 № 207-пр, 07.11.2024 № 652-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

3.6.3 пунктта:

дүртенче абзацта «Бүлек белгече әзерләгән» сүзләрен «Гариза бирүче таләбе буенча документларны кабул итүдән баш тарту язмача әзерләнә.» сүзләре белән алмаштырырга;

җиденче абзацны «телдән» сүзеннән соң «(язмача)» сүзе белән тулыландырырга;

3.9.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.9. Бүлек белгече күрсәтелгән проектлар буенча кимчелекләр бәян ителгән хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм җиренә җиткереп эшләнгән аренда шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен кабаттан хокук идарәсе башлыгына юллый.»;

Административ регламентка 3 нче кушымтаның 13 пунктында «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга:

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 584-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 22.05.2023 № 340-пр, 08.05.2024 № 268-пр, 23.01.2025 № 26-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәреш кертү турында:

2.8.2 пунктның унөченче абзацында «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга:

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

3.6.3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен телдән

аңлатып, гариза бирүчегә кайтара. Гариза бирүче таләбе белән документлар кабул итүдән баш тарту язмача әзерләнә.»;

3.6.3 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген телдән (язмача) аңлату, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.»;

3.9.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.9. Бүлек белгече күрсәтелгән проектлар буенча кимчелекләр бәян ителгән хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын кабаттан килештерергә дип Хокук идарәсе башлыгына юллый.».